РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ БАЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

*423983, РТ, Муслюмовский район, с. Баюково, ул. Советская 2*
*тел. (8-85556)3-16–38*

Баек авылы 01 февраля 2019 года

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XXXVIII УТЫРЫШЫ

## КАРАР № 1

**Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советы һәм Башкарма комитеты тарафыннан уздырылачак төп чаралар планын раслау турында**

«Баек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 32нче маддәсе, һәм ТР Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге башлыгының отчет докладына нигезләнеп, Баек авыл җирлеге Советы утырышы карар бирә:

1. Баек авыл җирлеге Башкарма комитет вазыйфаларын башкаручы Фахерлегаянов М.Ф. отчет докладын игътибарга(исәпкә) алырга.
2. Утырышта яңгыраган мәсьәләләр һәм тәкъдимнәр буенча чаралар планын төзергә һәм расларга (№1 һәм № 2 Кушымталар).
3. Әлеге карарның үтәлеше өчен җаваплылыкны Баек авыл җирлеге Башкарма комитет вазыйфаларын башкаручыга йөкләргә.

**Мөслим муниципаль районы**
**Баек авыл җирлеге Советы**
**утырышында рәислек итүче,**
**Баек авылы Советы**
**рәисе урынбасары:** **А.Ф.Хазиева**

«01» февраль, 2019 ел, № 1нче
Карарына 1нче кушымта «Раслыйм»
Баек авылы Советы рәисе
урынбасары ________ А.Ф.Хазиева

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Баек авыл җирлеге Советы тарафыннан 2019 елда уздырылачак**
**Төп чаралар планы**

Гыйнвар - февраль

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең 2018 елда социаль – икътисадый үсеше һәм 2019 елга бурычлары турында.
2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең 2018 ел бюджеты үтәлеше турында.
3. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советы депутатларының сайлау округларындагы эшчәнлеге турында мәгълүмат.
4. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең норматив- хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү турында.
5. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге эшчәнлеге турында Баек авыл Советы Башлыгының хисабы.

Март –апрель

1. 2019 елгы язгы ташу чорында биналарның, күперләрнең, гидротехник һәм башка корылмаларның саклануышын тәэмин итү турында.
2. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советы депутатларының сайлау округларындагы эшчәнлеге турында мәгълүмат.
3. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегендә физик культура һәм спорт үсеше турында.
4. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегендә законлылык, хокук тәртибе һәм хокук бозуларны профилактикалауның торышы турында.
5. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегендә әйләнә-тирә мохитне саклау һәм төзекләндерү турында.

Май – июнь

1. Баек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында.

2. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының 2019 елның 1 кварталында социаль – икътисадый үсеше турында.
3. 2019 елда мәгариф учреждениеләренең БДИ үткәрүгә әзерлекнең барышы турында.

Июль – август

1. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының 2019 елның 1 яртыеллыгына бюджет үтәлеше турында.
2. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының предприятие һәм учреждениеләренең яңа ягу сезонына әзерлеге турында.
3. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының 2019 елның 6 аенда социаль –икътисадый үсеше турында.

Сентябрь – октябрь

1. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының 2019 елның 9 аена тәгаенләнгән бюджетына үзгәрешләр кертү турында.
2. Баек авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләре турындагы законнарның үтәлеше турында.
4. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының 2020 елга бюджет проекты турында (1 укылыш).

Ноябрь - декабрь

1. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 аенда бюджет үтәлеше һәм Баек авыл җирлегенең аныкланган бюджетына үзгәрешләр кертү турында.
2. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советы тарафыннан 2020 елга ниятләнгән төп чараларны раслау турында.
3. Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Советының 2020 елга бюджеты турында (2 укылыш).

«01» февраль, 2019 ел, № 1нче
Карарына 2нче кушымта «Раслыйм»
Баек авылы Советы рәисе
урынбасары ________ А.Ф.Хазиева

**Баек авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елга**

**ЭШ ПЛАНЫ**

| № | Ч А Р А Л А Р | ВАКЫТЫ | ҖАВАПЛЫ КЕШЕ |
|---|---|---|---|
| | **ГЫЙНВАР** | | |
| 1 | Яңа ел чоры бәйрәм көннәрендә халыкның ялын оештыру (махсус план буенча) | 01-08.01.19 | Клуб мөдире, Баек авыл җирлеге, мәктәп |
| 2 | Иске стиль буенча Яңа елны каршылау бәйрәме | 13.01.2019 | Клуб мөдире |
| 3 | 2017 ел өчен отчетлар әзерләү һәм тапшыру | 2018 ел, декабрь | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| 4 | Үзешчән Театр коллективларының район конкурсында катнашу | 2019 ел | Мәдәният йорты |
| 5 | 2019 елга район социаль яклау бүлеге өчен төрле категория гаиләләрнең мәгълүматлар базасын формалаштыру | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| 6 | 2019 елга авыл җирлеге учреждениеләре өчен электр энергиясен куллану лимитын төзү буенча документлар әзерләү | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, Башкарма комитет бухгалтеры |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | Җир кишәрлеген файдаланучылар (инвесторлар) белән гомумөлешле милек җир кишәрлеген арендалау шартнамәләрен төзүне яңарту | Ай дәвамында | Авыл җирлеге Башлыгы |
| 8 | Баек авыл җирлеге Советының чираттагы сессиясе, Башкарма комитет эше турында хисап | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| | **ФЕВРАЛЬ** | | |
| 1 | Үзара салым мәсьәләләре буенча халык белән эшләү | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 2 | Ватанны саклаучылар көненә багышланган чаралар – «Ягез әле, егетләр!» кичәсе | 23.02.2019 | Клуб мөдире |
| 3 | Үзешчән сәнгать смотр-концертында катнашу | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма җитәкчеләре |
| 4 | Мөслим муниципаль районы авыл җирлекләре арасында XXVIII кышкы Спартакиадада катнашу | График буенча | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма җитәкчеләре |
| | **МАРТ** | | |
| 1 | Тематик кичә оештыру. Китапханәдә наркомания һәм наркобизнеска каршы көрәш көне уңаеннан күргәзмәләр оештыру | 01-08.03.2019 | Китапханәче |
| 2 | Халыкара хатын-кызлар көне - 8 мартка багышлап, «Ягез әле, кызлар!» күңел ачу конкурсы | 07-08.03.2019 | Клуб мөдире |
| 3 | Мәктәптә һәм балалар бакчасында «Нәүрүз» бәйрәме уздыру | Март | Укытучылар, тәрбиячеләр |
| 4 | Халык белән очрашулар оештыру | Ай дәвамында | Клуб мөдире, авыл җирлеге |
| 5 | Сайлаулар уздыру | 18.03.2019 | Участок сайлау комиссиясе, АҖ Башкарма комитеты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **АПРЕЛЬ** | | | |
| 1 | «Көлке көне»нә багышланган чаралар | 01.04.2019 | Клуб мөдире |
| 2 | Китапханәдә Бөек Җиңүнең 74 еллыгына багышланган чаралар әзерләү һәм үткәрү | Ай дәвамында | Китапханәче |
| 3 | Өмәләр оештыру | Ай дәвамында | Авыл җирлеге Башлыгы |
| 4 | «Хәрби хезмәткә чакырылучылар көне»н оештыруда ата-аналарның катнашуын тәэмин итү | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 5 | Бөек Җиңүнең 74 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган чараларга әзерлек | Ай дәвамында | Баек авыл җирлеге, бюджет оешмалары |
| **МАЙ** | | | |
| 1 | «Яз һәм хезмәт» бәйрәменә һәм «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү көне»нә багышланган чаралар үткәрү | 01-09.05.19 | Башкарма комитет җитәкчесе,<br>оешма җитәкчеләре |
| 2 | Бөек Җиңүнең 74 еллыгына багышланган митинг тантаналы үткәрү | 08.05.2019 | Башкарма комитет җитәкчесе,<br>оешма җитәкчеләре |
| 3 | Язгы кыр эшләрен барышын оештыру һәм үткәрү | Ай дәвамында | |
| 4 | Газета-журналларга язылу мәсьәләсе буенча халык арасында аңлату-агитация эше алып бару | Ай дәвамында | Почта бүлекчәсе мөдире,<br>Башкарма комитет җитәкчесе,<br>оешма җитәкчеләре |
| 5 | Авыл җирлеге яшьләре өчен "Яз көне»нә багышланган күңел ачу кичәсе | 01.05.2019 | Клуб мөдире |
| 6 | «Сабантуй» бәйрәмен үткәрүгә әзерлек чаралары | Айның икенче | Клуб мөдире,<br>Башкарма комитет |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | яртысында | җитәкчесе,<br>оешма җитәкчеләре,<br>депутатлар |
| 7 | Баек авыл җирлеге торак пунктларын яшелләндерү эшләрен оештыру | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе,<br>оешма җитәкчеләре |
| **ИЮНЬ** | | | |
| 1 | «Балаларны халыкара яклау көне»нә багышланган чаралар | 01.06.2019 | Балалар учреждениеләре җитәкчеләре |
| 2 | Халыкны һәм учреждениеләр хезмәткәрләрен яшел азык әзерләүгә мобилизацияләү | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе,<br>оешма җитәкчеләре,<br>хуҗалык зоотехнигы |
| 3 | «Сабантуй - 2019" милли бәйрәмен әзерләү һәм үткәрү | Ай башында | Башкарма комитет җитәкчесе,<br>бюджет оешмалары җитәкчеләре,<br>клуб мөдире |
| 4 | 2019-2020 еллар җылылык (ягу) сезонына әзерлек буенча чаралар планы | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе,<br>оешма җитәкчеләре |
| 5 | 2019-2020 елгы җылыту сезонына котельныйларны әзерләү буенча эш | Ай дәвамында | Газ хуҗалыгы, газ миче өчен җаваплы эшчеләр |
| **ИЮЛЬ** | | | |
| 1 | Авыл халкын һәм учреждение хезмәткәрләрен ашлык урып-җыю өчен мобилизацияләү (ындыр табагына) | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 2 | Бюджет оешмаларын 2019-2020 елгы җылыту сезонына әзерләү | Ай дәвамында | Оешма җитәкчеләре |
| **АВГУСТ** | | | |
| 1 | Авыл кырларында агитбригадалар эше | Ай | Клуб мөдире |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | дәвамында | |
| 2 | Ындыр табагында эшләү өчен халыкны һәм учреждениеләр хезмәткәрләрен мобилизацияләү | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма җитәкчеләре |
| 3 | Халык арасында «Физкультурачылар көне» бәйрәмен әзерләү һәм үткәрү | 11.08.2019 | Башкарма комитет җитәкчесе, физкультура укытучысы |
| 4 | Җир кишәрлекләре өчен аренда түләүләрен вакытында кертүне контрольдә тоту | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| | **СЕНТЯБРЬ** | | |
| 1 | Баек урта белем бирү мәктәбендә Белем көне | 01.09.2019 | Мәктәп директоры |
| 2 | Бюджет оешмаларын ягу сезонына әзерләү һәм котельняларга газ тоташтыру | Ай дәвамында | Оешма җитәкчеләре, Башкарма комитет җитәкчесе |
| 3 | Җир һәм милек салымын җыюны оештыру | Ай дәвамында | Башкарма комитет сәркатибе |
| 4 | «Өлкәннәр көне»н үткәрүгә әзерлек | 01.10.2019 | Авыл җирлеге Башлыгы, Баек авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| | **ОКТЯБРЬ** | | |
| 1 | Өлкән кешеләрне хөрмәтләү | 01.10.2019 | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма җитәкчеләре |
| 2 | 2019-2020 елгы җылылык сезонына әзерлек буенча чараларны тәмамлау | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма җитәкчеләре |
| 3 | Көзге бал (уеннар, конкурслар, КВН) | Ай дәвамында | Клуб мөдире |
| | **НОЯБРЬ** | | |
| 1 | «Әниләр көне»нә багышланган чаралар; әниләр һәм балалар | Ай дәвамында | Клуб мөдире, китапханәче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | катнашында конкурслар | | |
| | **ДЕКАБРЬ** | | |
| 1 | Инвалидлар ункөнлеге. «Инвалидлар көне»нә багышланган чаралар | 01.12-10.12.19 | Башкарма комитет җитәкчесе, авыл җирлеге депутатлары |
| 2 | Авыл җирлекләре үзешчән театр коллективлары арасында узачак конкурста катнашуга әзерлек | Ай дәвамында | Клуб мөдире |
| 3 | Яңа ел бәйрәмен үткәрү өчен мәйдан һәм залны әзерләү, бизәү | 20.12.19 дан 31.12.19 га кадәр | Клуб мөдире, Башкарма комитет җитәкчесе |
| 4 | 2020 елга вакытлы матбугатка язылу мәсьәләсе буенча халык арасында аңлату-агитация эше үткәрү | Ай дәвамында | Почта бүлекчәсе мөдире, Башкарма комитет җитәкчесе, оешма җитәкчеләре |
| 5 | Баек авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елга эш планын төзү | 31.12.2019 кадәр | Башкарма комитет җитәкчесе, сәркатибе |
| 6 | Бюджет сессиясен үткәрү | Ай дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 7 | Бал-маскарад уздыру | 31.12.2019 | Клуб мөдире |